ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КЛЮЧЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ БУГУЛЬМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЛЮЧИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.09.2019 ел № 36

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы
Ключи авыл җирлеге Башкарма комитетының
2019 елның 9 гыйнварында кабул иткән
“Адреслар билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән алу буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында”гы
7нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

2019 елның 26 июлендә кабул ителгән “Федераль мәгълүмати адреслар системасы турындагы һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында”гы №227-ФЗ законына таянып, законга туры китерү максатында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Ключи авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 9 гыйнварында кабул иткән “Адреслар билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 7нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5нче пунктның 3нче абзацында “планлы структура элементын (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементын” дигән сүзләрне “урам -юл челтәре элементын һәм (яки) планлы структура элементы атамасын (кирәк булганда)” дигән сүзләр белән алыштырырга.

1.2. 1.5нче пунктның 5нче абзацын түбәндәге басмада бәян итәргә:

“адреслаштыру объекты – капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган адреслаштыру объектлары исемлегендә каралган башка объект;”.

2. Карар текстының башка өлешен үзгәрешсез калдырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**В.А. Батаев**